**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Сухояшского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

ул. Школьная, д. 4-2, село Большой Сухояш,
Азнакаевского муниципального района, 423325
Тел. (факс) 34-6-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Мәктәп урамы, 4-2, Зур Сукаеш авылы
Азнакай муниципаль районы, 423325
Тел. (факс) 34-6-16

24.04.2020г. № 8

**П О С Т А Н О В Л Е Н И Е** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитетының 04.02.2019 елның 2 номерлы "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында" карары белән расланган административ регламентларга үзгәрешләр кертү турында (05.08.2019 елның 10 номерлы, 27.02.2020 елның 5 номерлы карарлар редакциясендә)

2020 елның 01 мартындагы 35-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына ана (гаилә) капиталы средстволарын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә, Сукаеш авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитетының 04.02.2019 елның 2 номерлы "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында" карары белән расланган административ регламентларга (05.08.2019 елның 10 номерлы, 27.02.2020 елның 5 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны, муниципаль торак фонды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында

а) 2.5 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) гариза бирүче-гражданның гаилә составы турында документлар күчермәләре (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ. б.);»;

б) 2.5 пунктының 5 пунктчасында өченче, дүртенче абзацларны төшереп калдырырга.

1.2. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондыннан торак урыннарын алмаштыру буенча документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында 2.5 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) гариза бирүче гражданнарның гаилә составы турында документлар күчермәләре (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ.б.);».

1.3. Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында 2.5 пунктының 7 пунктчасын төшереп калдырырга.

1.4. Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында 2.5 пунктының 7 пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Закирова З.Җ.